КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 февраль г.Казань № 44

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга дәүләт экспертизасы турында» 2019 ел, 30 март, 251 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга дәүләт экспертизасы турында» 2019 ел, 30 март, 251 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга дәүләт экспертизасын уздыру тәртибендә:

4.3 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$S_{1, 2,... n} = M + K_n \times M$,»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«фәннәр кандидатының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен - 0,1 процент күләмендә;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«фәннәр докторының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен - 0,2 процент күләмендә.»;

әлеге карар белән расланган Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга дәүләт экспертизасын уздыру буенча эксперт советы составын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 март, 251 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 1 февраль, 44 нче
карары редакциясендә)

## Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга дәүләт экспертизасын уздыру буенча эксперт советы составы

| | |
|---|---|
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, эксперт советы рәисе |
| Мифтахова Алсу Равил кызы | «Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау буенча ресурс үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, эксперт советының җаваплы секретаре |

Эксперт советы әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Белоусова Людмила Даниловна | «Я.Е.Емельянов исемендәге мәдәни үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе |
| Габдрахманова Гөлнара Зәкәрия кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесенең этнологик тикшеренүләр бүлеге мөдире |
| Гомәров Илһам Госман улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире |
| Гущина Елена Геннадьевна | Этнография музее директоры, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы мәктәбе югары мәктәбенең антропология һәм этнография кафедрасы доценты (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Донина Лариса Николаевна | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесенең өлкән фәнни хезмәткәре |
| Ильясов Рәсим Әдгам улы | Югары сәнгать мәктәбе деканы вазыйфаларын башкаручы, «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең музыка башкаруы кафедрасы доценты (килешү буенча) |
| Кашапова Эльмира Вафи кызы | «Бермәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе сәнгать җитәкчесе; |
| Колчева Эльмира Мәҗит кызы | «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең музеология, культурология һәм сәнгать белеме кафедрасы доценты (килешү буенча) |
| Комар Наталья Геннадьевна | «А.С.Пушкин исемендәге мәдәни үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Макаров Геннадий Михайлович | «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерв-аториясе» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең татар музыкасы һәм этномузыка кафедрасы доценты (килешү буенча) |
| Мостакимов Ильяс Альфред улы | «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге әйдәүче фәнни хезмәткәре |
| Мөхәммәтҗанова Лилия Хатыйп кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге әйдәүче фәнни хезмәткәре |

| | |
|---|---|
| Напольских Владимир Владимирович | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы мәктәбе югары мәктәбенең антропология һәм этнография кафедрасы мөдире вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Самойлова Александра Васильевна | «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең этносәнгать иҗаты һәм музыка белеме кафедрасы доценты (килешү буенча) |
| Сәрвәрова Лилия Илдус кызы | «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең татар музыкасы һәм этномузыка кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| Саттарова Лилия Ил кызы | «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Музей әйберләрен исәпкә алу һәм саклау буенча генераль директор урынбасары - төп саклаучысы |
| Сөләйманова Гүзәл Фуад кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесенең баш фәнни хезмәткәре |
| Солтанова Рауза Рифкать кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының рәсем һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире |
| Шкляева Людмила Михайловна | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының рәсем һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре. |